КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 март г.Казань № 228

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 25 апрель, 326 нчы карары белән расланган Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 25 апрель, 326 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июнь, 467 нче; 2020 ел, 11 июль, 574 нче; 2021 ел, 29 май, 390 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

расланган Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта «2020 елның 1 октябреннән 2021 елның 30 ноябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 маеннан 2022 елның 30 ноябренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктта:

икенче абзацта «заявка бирү көненә» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына «Россия Федерациясе Пенсия фонды Идарәсенең 2021 елның 15 апрелендәге 103п номерлы карары белән расланган «Иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар (СЗВ-М)» формасы буенча белешмә мәгълүматлар (алга таба – иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар) бирү бурычын башкара.»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«салым органының сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 20 се хәленә карата Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларның торышы турында белешмә кәгазьләре формаларын, аларны тутыру тәртибен һәм белешмә кәгазьләрен электрон рәвештә бирү форматларын раслау хакында» 2016 елның 28 декабрендәге ММВ-7-17/722@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча оешмаларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар,процентлары буенча исәп-хисаплары торышы турында белешмә кәгазен.»;

3.2 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Заявкаларны кабул итү вәкаләтле оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында, заявкалар кабул ителә башлау көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау даталары (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле оешманың исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 5.4 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә заявка бирүчеләргә карата таләпләр һәм заявка бирүченең әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен аның тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 3.1 – 3.4 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 4.2 – 4.6 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

заявка бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый);

әлеге критерийлардан чыгып сайлап алына торган, субсидия алу хокукына ия булган заявка бирүчеләрне сайлап алу критерийлары.»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Вәкаләтле оешма сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән заявкаларны кабул итү срогы чыккан көннән соң килә торган эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә заявка бирүченең һәм аның тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1, 2.2, 3.1 – 3.4 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килү-килмәвен тикшерә һәм вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат формалаштыра.

Вәкаләтле оешма, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән соң өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле орган тарафыннан расланган формалар буенча заявканы кабул итмәү турында яки сайлап алуда җиңүче дип тану һәм субсидия бирү турында карарлар кабул итү өчен заявканы һәм әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны вәкаләтле органга җибәрә.

Вәкаләтле орган заявкаларны карап тикшерә һәм алар вәкаләтле оешмадан кергән көннән 15 эш көненнән артмаган срокта вәкаләтле орган тарафыннан расланган формалар буенча заявканы кабул итмәү турында яки сайлап алууда җиңүче дип тану һәм субсидия бирү турында карарлар кабул итә, .

Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

заявка бирүченең әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве;

тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә заявкаларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявка бирүче тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң заявка бирү;

заявка бирүченең әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган сайлап алу критерийларына туры килмәве;

әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок чыкканга кадәр заявка бирүче тарафыннан, бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек күләмдә булмавына бәйле рәвештә субсидия күләмен киметү турындагы хәбәрнамәгә җавап итеп, әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча язмача ризалыгы бирелмәү;

әлеге Тәртипнең 3.1 – 3.4 пунктларында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

заявка бирүче тарафыннан агымдагы календарь елда әлеге Тәртипнең 5.3 пунктында каралган субсидиянең иң чик күләме алыну;

бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән карарлар кабул ителгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, заявканы һәм әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән карарларны вәкаләтле оешмага тапшыра.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән карарлар кабул ителгән көннән соң килә торган өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында түбәндәге белешмә мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән заявка бирүчеләр турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән заявка бирүчеләр турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

сайлап алуны үткән, килешүләр төзелә торган заявка бирүчеләр исеме һәм аларга бирелә торган субсидияләр күләмнәре.»;

5.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидиянең иң чик күләме агымдагы календарь елда бер субсидия алучыга 3 млн.сумнан арта алмый.»;

5.5  пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Субсидия алучы вәкаләтле оешмага, килешү төзелгән айдан соң килә торган өченче айга иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар күчермәләрен (пенсия фонды органнарының хисаплылыкны кабул итү турындагы билгесе белән яисә электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон төрдәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турында документлар белән бирелә) теркәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисаплылык кертә. Субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турындагы хисаплылык субсидия алучы тарафыннан, хисап чоры тәмамланган көннән соң килә торган 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле оешмага кәгазьдә тапшырыла. Хисап чоры – килешү төзегән айдан соң килә торган өченче ай.»;

5.6 пунктта:

дүртенче абзацта «субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләренә

алмаштырырга;

алтынчы абзацта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

Тәртипкә 2 нче кушымтада:

унөченче абзацта «заявка бирү көненә» сүзләрен төшереп калдырырга;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына «Россия Федерациясе Пенсия фонды Идарәсенең 2021 елның 15 апрелендәге 103п номерлы карары белән расланган «Иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар (СЗВ-М)» формасы буенча белешмә мәгълүматлар бирү бурычын башкара».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин